**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТЕНЕШ**
**ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЁЛОГЫ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**
**ПОСЁЛОК СОВЕТЫ**

---

# КАРАР

Тенишево ш.т.п. № 26-рс

**Поселок Советы тарафыннан 2021 елның 29 июнендә кабул ителде**
**Тенеш поселогы башлыгы тарафыннан 2021 елның 29 июнендә имзаланды**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 декабрендәге 122-рс номерлы Совет карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге советына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш өстәргә:
«3.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициатив проектны тәкъдим итә ала.».

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т.п., Ленин ур., 8 йорт; Татарстан Республикасы, Кама Тамагы

муниципаль районы, Тенеш ш.т.б., Пионер ур., 18 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка хәбәр ителгән (бастырып чыгарылган) көненнән үз көченә керә..

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башлыгына йөкләргә.

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, «Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге Советы рәисе | И. Т. Гыйниятов |